ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КАМАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ
КАМАЙ АВЫЛЫНДА
ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

2019 елның 30 ноябреннән № 1

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Камай авыл җирлегенең
Камай авылында гражданнар җыены
нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлегенең Камай авылында гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлегенең Камай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Үзара салым акчаларын түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- видеокүзәтү сатып алу һәм урнаштыру;
- юлларны кардан чистарту;
- татар телендә урам исемнәрендәге күрсәткечләр сатып алу һәм урнаштыру;
- янгын гидрантларын ремонтлау;
- янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру;
- генератор сатып алу

3. Камай авылының мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru «Камай авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Камай авыл җирлеге башлыгы И.И. Әһлиева